**СОВЕТ БИРЮЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422737, Республика Татарстан, Высокогорский район
п.Бирюлинского зверосовхоза, ул.В.Интернационалистов,д.3Б

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӨРЕЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422737, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Бөреле җәнлек совхозы пос., В.Интернац ур., 3Б

Тел./факс: +7(84365) 76-5-45, e-mail:Brl.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ**
**17 июня 2024 ел.**

**КАРАР**
**№ 86**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Бөреле авыл җирлеге Уставы, Бөреле авыл җирлеге советы нигезендә КАРАР БИРДӘ:

1. Аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнүче 2024 елның 1 гыйнварына җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычы булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнелә торган бурыч булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслый торган документлар түбәндәгеләр дип билгеләргә:

1) әлеге Карарның 1 пунктының 1 бүлегендә күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлүгә бәйле рәвештә салым органнарында исәпкә алынганнан соң физик затны төшерү турында белешмәләр;

в) мираска хокук турында таныклык бирү турында белешмәләр булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге Карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) оешма, шәхси эшкуар, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик зат исәбе буенча салым органы белешмәсе, бурыч суммасы турында;

б) салым бетерелгән норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында белешмәләр;

3) әлеге Карарның 1 пунктының 3 бүлегендә күрсәтелгән нигез булганда, - салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч барлыгы турындагы белешмәсе.

3. Бөреле авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммасында бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 26 маендагы 58 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән: http://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет председателе,
Бөреле авыл җирлеге башлыгы Т.Х.Багаутдинов